Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары,
Бөтендөнья татар конгрессының
Милли Шура рәисе
_______________ В.Г. Шәйхразыев

Бөтендөнья татар хатын-кызлары
форумы җитәкчесе,
Региональ татар хатын-кызлары
«Ак калфак» иҗтимагый оешмасы рәисе
_______________ К.Р. Идрисова

# В. МАЛИКОВ ИСЕМЕНДӘГЕ II БӨТЕНРОССИЯ “СЫНЧЫ” СЫНЛЫ СӘНГАТЬ БӘЙГЕСЕ НИГЕЗЛӘМӘСЕ

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘ

1.1. В. Маликов исемендәге II Бөтенроссия “Сынчы” сынлы сәнгать Бәйгесе (алга таба – Бәйге) халык сәнгате традицияләрен саклау һәм үстерү, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТАССРның халык рәссамы, РСФСРның атказанган рәссамы Маликов Васыйл Малик улының иҗади мирасын популярлаштыру, Россия Федерациясендә һәм аннан читтә эстетик тәрбия бирү максатыннан үткәрелә.

1.2. Бәйге 2026 елның маеннан 10 октябренә кадәр түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

- **Милли традицияләрне куллану**;
- **Яңалык һәм үзенчәлек**;
- **Памятниклар проектлары (фонтаннар, авыл һәм шәһәр мохитендәге кечкенә архитектура формалары);**
- **Академик рәсем.**

## 2. БӘЙГЕНЕҢ МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

2.1. Бәйгенең максаты – декоратив-гамәли сәнгатенең заманча формаларында халык традицияләрен саклау һәм үстерү өлкәсендә балалар һәм үсмерләрнең иҗади мөмкинлекләрен ачыклау.

2.2. Бәйгенең бурычлары – Россия Федерациясе халыкларының әдәби мирасын яшь буынга җиткерү, сәләтле балаларны ачыклау һәм аларны үстерү, иҗади берләшмәләр вәкилләре арасында тәҗрибә уртаклашу.

## 3. БӘЙГЕНЕ ОЕШТЫРУ КОМИТЕТЫ

3.1. Бәйгене гамәлгә куючылар һәм оештыручылар булып Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты, “Ак калфак” татар хатын-кызларының төбәк иҗтимагый оешмасы тора.

3.2. Бәйгены оештыру, уздыру һәм нәтиҗәләрен чыгару өчен Бәйгенең гамәлгә куючылары һәм оештыручылары вәкилләреннән торган оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) төзелә.

## 4. БӘЙГЕНЕҢ КАТНАШУЧЫЛАРЫ

4.1. Бәйгедә 7 яшьтән алып 23 яшькә кадәрге Россия Федерациясенең муниципаль гомумбелем бирү, шәхси гомумбелем бирү учреждениеләре укучылары, мәдәният-ял итү учреждениеләренең балалар иҗат берләшмәләре катнашучылары, шулай ук 23 яшькә кадәрге студентлар, билгеләнгән срокларда гариза биргән һәм эшләрен тапшырган очракта, катнаша алалар.

## 5 БӘЯЛӘҮ КРИТЕРИЙЛАРЫ

5.1.Барлык номинацияләр өчен бәяләү критерийлары:

–сәнгати нияте тулы чагылыш тапкан булуы (0-10 балл);
–һөнәрчелек традицияләрен куллану (0-10 балл);
–яңалык һәм оригинальлек (0-10 балл);
–темага туры килүе (0-10 балл);
–эш башкару осталыгы (0-10 балл);
–иҗади якын килү (0-10 балл);
–эшнең эстетик күренеше (рәсемне бизәү) (0-10 балл).

5.2. Эшләр түбәндәге яшь төркемнәренә карап бәяләнә:

1 төркем: 7–10 яшь (рәсем мәктәбе)
2 төркем: 11–15 яшь (рәсем мәктәбе)
3 төркем: 16–23 яшь (студентлар)

## 6. БӘЙГЕНЕ ҮТКӘРҮ ТӘРТИБЕ

6.1. Иҗади эшләрне булдыру чыганагы итеп В. Маликовның барлык иҗади мирасы алына.

6.2. Бәйге өчен бары тик шәхси тәртиптә башкарылган эшләр кабул ителә. Бер катнашучы 2 эштән артык тәкъдим итә алмый.

6.3. Бәйге эшенең арткы ягына беркетелгән түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш: эшнең исеме, үлчәмнәре, башкару техникасы, номинация, авторның фамилиясе, исеме һәм яше (туган елы), мәктәбенең, районының, краеның, өлкәсенең, республикасының, яшәгән иленең исеме.

## 7. БӘЙГЕНЕҢ ЖЮРИ ӘГЪЗАЛАРЫ

7.1. Бәйгенең жюри әгъзалары мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге белгечләрдән тора.
7.2. Жюри утырышы, әгәр кимендә өч жюри әгъзасы катнашса, хокуклы дип санала.
7.3. Баллар нигезендә жюри әгъзалары һәр номинация буенча җиңүчеләр исемлеген формалаштыра.
7.4. Жюри карары күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм протокол белән рәсмиләштерелә.

## 8. БӘЙГЕНЕ ОЕШТЫРУ ТӘРТИБЕ

8.1. Бәйгедә катнашу бушлай.
8.2. Бәйге ике этапта үткәрелә.
8.3. I этап – 2026 елның маеннан 10 октябренә кадәр гаризаларны, фото һәм видео материалларны электрон почта аша (ak.kalfak@mail.ru) җибәрү.
Бәйгедә катнашырга теләүчеләр JPEG форматында үзләренең иҗади эшләренең фотоларын һәм гаризаны (2-нче кушымта) жюри әгъзаларына электрон адрес буенча юллыйлар.

II этап – йомгаклау этабы. 2026 елның ноябрендә үткәрелә.

## 9. НӘТИҖӘЛӘР ЧЫГАРУ ҺӘМ БҮЛӘКЛӘҮ

9.1. II – йомгаклау этабына узган Бәйге катнашучылары номинант дип игълан ителә.
Һәр яшь төркемендә беренче, икенче, өченче урыннарны алган эшләр авторлары Бәйгенең Лауреаты исемен ала. Калган катнашучыларга – Дипломант исеме бирелә.
9.2. Җиңүчеләр исемлеге Бөтендөнья татар конгрессының рәсми сайтында (https://tatar-congress.org/ru/) урнаштырыла.
9.3. Бәйгенең бүләкләү кичәсе тантаналы рәвештә Лауреатлар һәм Дипломантлар эшләренең күргәзмәсе ачылышы кысаларында үткәрелә.
9.4. Бәйге лауреатлары һәм дипломантлары Диплом һәм кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнә.

*Кушымта №1*

Жюри әгъзалары исемлеге

| | |
|---|---|
| Миңнулина<br>Асыя Минвәли кызы | сынчы-рәссам, Бакый Урманче, Тукай премияләре лауреаты. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, РФ һәм ТР рәссамнар берлеге әгъзасы, бәйгенең жюри рәисе |
| Нургалиева<br>Розалия Миргалим кызы | Татарстан Республикасының атказанган архитекторы, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее директоры |
| Идрисова<br>Кадрия Рәис кызы | Бөтендөнья татар хатын-кызлары форумы җитәкчесе, Региональ татар хатын-кызлары «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы рәисе, филология фәннәре кандидаты |
| Фәсхетдинова<br>Луиза Фәһим кызы | рәссам-этнодизайнер, Әмир Мәҗитов музее мөдире, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Бакый Урманче исемендәге премия лауреаты |

*Кушымта №2*

**В. Маликов исемендәге “Сынчы” II Бөтенроссия сынлы сәнгать бәйгесенең гаризасы**

1.Исеме, фамилиясе, әтисенең исеме________________________________________
________________________________________________________________

2. Туган көне, ае, елы ______________________________________________

3.Бәйгегә тәкъдим ителгән эшнең исеме____________________________________
________________________________________________________________

4. Эшнең размеры, башкару техникасы, номинация ________________________
________________________________________________________________

5. Почта адресы ___________________________________________________

6. Электрон адрес __________________________________________________

7. Элемтә өчен телефон номеры _______________________________________
8. Мәктәп/урта махсус белем бирү учреждениесе, сыйныф/курс
________________________________________________________________

________________________________________________________________

9. Республика, төбәк, өлкә ___________________________________________

9. Җитәкче яки укытучы исеме _________________________________________
________________________________________________________________

10. Сәнгать мәктәбе, сыйныф (укыган очракта)__________________________
________________________________________________________________

Дата “_______”________________ 2025 ел.